## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

18 ноябрь 2022 ел

№ 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Югары Чыршылы авылында 2023 елда үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Югары Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2023 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Югары Чыршылы авылында су үткәргечне алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Югары Чыршылы авылында өлкәннәр көне үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

3) Югары Чыршылы авылында артезиан скважиналары территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары, буяу сатып алу, эшләр өчен түләү);

4) МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьлар сатып алу;

5) МТЗ-82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу;

6) Югары Чыршылы авылы зираты өчен чапкыч (триммер) сатып алу;

7) Югары Чыршылы авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

8) Югары Чыршылы авылында көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны җыештыру һәм чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү)

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов